| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **КАРАР** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| **10.02.2020** | Кукмара шәһәре | **№ 137** |

«2018 – 2020 елларга халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 20 декабрендәге 819 номерлы карары белән расланган «2018 – 2020 елларга халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
10.02.2020 елның 137 номерлы карарына
кушымта

**«2018 – 2020 елларга халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» муниципаль программасы**

ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның Исеме | «2018 – 2020 елларга халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны төп эшләүчеләр | «Кукмара муниципаль районы Гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максатлары:<br><br>Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән, янгыннардан һәм су объектларындагы һәлакәтләрдән халыкка, икътисадка һәм табигый мохиткә китерелгән социаль, икътисадый һәм экологик зыянны минимальләштерү.<br><br>Программаның бурычлары:<br><br>1. Янгыннар куркынычын, янгын нәтиҗәсендә һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән кешеләр саны кимүне дә кертеп, социаль яраклы дәрәҗәгә кадәр киметү;<br><br>2. Татарстан Республикасы халкының, территорияләренең һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән якланышын арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен йомшарту,<br>гражданнар оборонасы өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру;<br><br>3. Татарстан Республикасы су объектларында халыкның тормыш эшчәнлеге иминлеген арттыру;<br><br>4. Гражданнар оборонасы, янгын куркынычсызлыгы, |

<table>
<tr><td></td><td>халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау (алга таба – гадәттән тыш хәлләр) мәсьәләләре буенча төп норматив хокукый актлар таләпләрен тормышка ашыру;<br>5. ЕДДСны идарәне автоматлаштыруның программа-техник чаралары белән тәэмин итү;<br>6. Персоналның квалификациясен дәрәҗәсен күтәрү.</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программалар исемлеге</td><td>«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычын киметү һәм аларның нәтиҗәләрен йомшарту»</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2018 – 2020 еллар</td></tr>
<tr><td>Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары:</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме 5402,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br><table><tr><th>Финанслау чыганагы</th><th>2018 елы</th><th>2019 елы</th><th>2020 елы</th></tr><tr><td>Район бюджеты</td><td>1 857,3</td><td>1 392,9</td><td>2 152,7</td></tr><tr><td>барлыгы</td><td>1 857,3</td><td>1 392,9</td><td>2 152,7</td></tr></table>Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре</td><td>Программаны гамәлгә ашыру 2020 елга мөмкинлек бирәчәк:<br>- гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда барлык дәрәҗәдәге идарә органнарының җавап бирү вакытын 5 минутка киметү;<br>- җәлеп ителә торган көчләрнең һәм даими әзерлек чараларының үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген,<br>аларның гамәлләренең җайга салынуын,<br>килеп туган хәл турында аларның хәбәрдар булу дәрәҗәсен арттыру;<br>- беренче янгын бүлекләренең норматив килү вакытыннан читтә урнашкан торак пунктлар өлешен 0 процентка кадәр җиткерү;<br>- гадәттән тыш хәлләргә реакция белдерүгә әзерлекнең 100</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | процент дәрәҗәсен саклап калырга;<br>- су объектларында һәлак булган кешеләр санын киметергә;<br>- су объектларында һәлак булган балалар санын киметергә;<br>- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча дәүләт системасы идарәсенең (алга таба – РСЧС) барлык звеноларына үз вакытында хәбәр итү һәм координацияләү, шулай ук халык белән элемтә. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Программаны тормышка ашыруны контрольдә тота |

## I. Программа хәл итәргә тиешле проблеманың характеристикасы

Хәзерге шартларда техноген, табигый һәм террористик характердагы тискәре факторлар Татарстан Республикасының тотрыклы һәм куркынычсыз үсеше һәм халыкның тормыш сыйфатын арттыру өчен иң куркыныч янаучы факторларның берсе булып тора.

ЕДДС (Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте) булдыруның максаты – гадәттән тыш хәл килеп чыгу куркынычына җавап бирү, халыкка һәм оешмаларга аларның барлыкка килү фактлары һәм алар буенча кабул ителгән чаралар, җәлеп ителә торган көчләрнең һәм даими әзерлек чараларының үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеге һәм аларның җайга салынган уртак гамәлләре турында хәбәр итү оперативлыгын күтәрү.

РСЧСның башка көндәлек идарә органнарыннан ЕДДСның принципиаль аермасы – аның структурасында халык һәм оешмалардан гадәттән тыш хәлләр турында тәүлек буе хәбәр кабул итү, аларны эшкәртү һәм кызыксынган барлык ДДСларга (дежур-диспетчерлык хезмәте) оператив хәбәр итү өчен билгеләнгән РСЧС звеносында бердәм мәгълүмат киңлеген тәэмин итәргә, гадәттән тыш хәлләргә җавап бирүнең оперативлыгын һәм нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирә торган диспетчерлык сменасының булу. Ләкин хәзерге вакытта идарәнең төп объектлары турында исәпкә алынган төп мәгълүмат системалары үсешнең башлангыч стадиясендә тора.

Мәгълүмат җыю һәм эшкәртү процедуралары автоматлаштырылмаган. Программа гражданнарны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау дәрәҗәсен күтәрүгә, янгын куркынычсызлыгы һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итүгә, гражданнар оборонасы, кешеләрне коткару, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауга һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән халыкка ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән.

2012 – 2017 елларда Россия Федерациясе халкын һәм территорияләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау торышы турындагы дәүләт докладлары нигезендә, куркыныч табигать күренешләре һәм зур техноген катастрофалар саны ел саен арта бара. Бу климат үзгәрү, шулай ук Россия сәнәгать предприятиеләренең төп җитештерү фондларының 60 – 80 процентына кадәр тузган

булуы белән бәйле глобаль процессларга нәтиҗәсе.

Климатның глобаль үзгәрүе, хуҗалык эшчәнлеге барышында яисә зур техноген аварияләр һәм һәлакәтләр нәтиҗәсендә барлыкка килә торган табигый һәм техноген гадәттән тыш хәлләр хәвеф-хәтәрләре Татарстан Республикасы халкы һәм икътисад объектлары өчен зур куркыныч тудыра.

Хәзерге вакытта гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль подсистемасы (алга таба – ТП РСЧС) үз үсешенең яңа фазасына керә: беренче планга халыкның, территорияләрнең һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән сакланышын арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен йомшарту буенча тагын да максатчан эш таләпләре куела.

Әлеге стратегия гадәттән тыш хәлләрнең хәвеф-хәтәрләрен киметү өлкәсендә идарә итүне координацияләү механизмнарын үстерүгә, кризис һәм гадәттән тыш хәлләрдә ашыгыч ярдәм күрсәтү системасын оптимальләштерү, шулай ук заманча мәгълүмати-коммуникацион технологияләр һәм массакүләм мәгълүмат чараларының техник чаралары нигезендә тормыш эшчәнлеге иминлеге культурасын формалаштыру методларын һәм чараларын булдыруга юнәлтелгән чараларны үз эченә ала.

Республика территориясе тотрыксыз һава-климат шартлары булган зонада урнашкан, бу циклик характердагы табигый күренешләргә бәйле гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүгә алшартлар тудыра. Табигать бәла-казаларын фаразлау чараларында гадәттән тыш хәлләрне мониторинглау һәм фаразлау системасы мөһим роль уйный, ул саклык чараларын (превентив чаралар) планлаштырырга һәм үткәрергә мөмкинлек бирә.

Республика халкы һәм әйләнә-тирә мохите өчен уртача сроклы перспективада техноген характердагы хәвеф-хәтәрләр шактый куркыныч тудырачак. Татарстан Республикасы Идел буе федераль округында куркыныч җитештерү объектлары саны буенча алдынгы урында тора.

Кукмара муниципаль районы территориясендә 2 потенциаль куркыныч объект бар.

Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча хәлнең факттагы торышы муниципаль программа һәм ЕДДС үсеше проблемасына программа-максатчан якын килү зарурлыгына күрсәтә. Югарыда күрсәтелгән проблемаларны хәл итүгә әлеге Программа юнәлдерелгән.

## II. максатлары, бурычлары, сроклары (этаплары)

## һәм программаның максатларына ирешү һәм бурычларын хәл итү күрсәткечләре (индикаторлары)

Программаның максаты – табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән, янгыннардан һәм су объектларындагы һәлакәтләрдән халыкка, икътисадка һәм табигый мохиткә китерелгән социаль, икътисадый һәм экологик зыянны минимальләштерү.

Аңа ирешү өчен түбәндәге төп бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Янгыннар куркынычын социаль яраклы дәрәҗәгә кадәр киметү, шул исәптән янгын нәтиҗәсендә һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән кешеләр саны кимүне дә кертеп;

2. Кукмара муниципаль районы халкының, территорияләренең һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклануын арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен йомшарту, Гражданнар оборонасы өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру;

3. Кукмара муниципаль районының су объектларында халыкның тормыш иминлеген арттыру.

Программаны тормышка ашыру өлкәсе булып гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә нәтиҗәле эшчәнлекне оештыру тора.

Программаның максатларына ирешү һәм бурычларын хәл итү программаның бер ярдәмче программасында төркемләнгән төп чараларны үтәү юлы белән тәэмин ителә. Программаның аерым чаралары үзара бәйле. Бер чараның уңышлы үтәлеше башкаларның үтәлешенә бәйле булырга мөмкин.

«2018 – 220 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне киметү һәм аларның нәтиҗәләрен йомшарту» ярдәмче программасы түбәндәге чараларны үз эченә ала:

гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү;

гадәттән тыш хәлләрне һәм табигый бәла-казаларны кисәтү;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен финанс чаралары резервларын формалаштыру һәм тоту;

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы объектларының иминлек паспортларын эшләү һәм төзәтү;

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында нефть һәм нефть продуктларын таратуны кисәтү һәм бетерү буенча планнар эшләү;

гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында халыкка ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасын тоту;

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының дежур-диспетчерлык хезмәте эчтәлеге;

Кукмара муниципаль районы оператив дежурларының квалификациясен күтәрү;

Программаны тормышка ашыру вакыты: 2018 – 2020 еллар.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 5 402,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

| Финанслау чыганагы | 2018 ел, мең сум | 2019 ел, мең сум | 2020 ел, мең сум |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| Район бюджеты | 1 857,3 | 1 392,9 | 2 152,7 |
| Барлыгы | 1 857,3 | 1 392,9 | 2 152,7 |

Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## IV. Программаны тормышка ашыру механизмы

Планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияләүне һәм башкаруны контрольдә тотуны Программаны эшләүче башкара, ул ел саен максатчан күрсәткечләрне һәм Программа чараларына чыгымнарны, аны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручылар составын ачыклый, чараларны үтәү өчен җаваплы кешеләрдән Программаны үтәү барышы турындагы мәгълүматны соратып ала.

Программаны тормышка ашыру, аларны үтәү срокларын, бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеген үз эченә алган еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручылар программаны эшләүчегә чараларның үтәлеше һәм башкаручыларга бүлеп бирелә торган акча средстволары турында үсеш нәтиҗәсе белән һәм тулаем алганда хисап елы өчен мәгълүмат бирәләр.

Программага үзгәрешләр кертү Программа чараларын җаваплы башкаручы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программага кушымта

Программа чаралары исемлеге

| № т/б | Чараның исеме | Башкаручы | Вакыты елы | Финанслау юнәлешләре әм чыганаклары | Еллар буенча бүленеш | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | Учреждениенең хезмәт хакы фонды | «Кукмара муниципаль районы Гражданлык яклау идарәсе» МКУ | 2018 – 2020 еллар | Кукмара МР бюджеты | 1228,4 | 980,2 | 874,0 |
| 2 | Хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү буенча мәҗбүри социаль иминият взнослары һәм учреждениеләр хезмәткәрләренә башка түләүләр | «Кукмара муниципаль районы Гражданлык яклау идарәсе» МКУ | 2018 – 2020 еллар | Кукмара МР бюджеты | 379,6 | 287,3 | 264,0 |
| 3 | Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу | «Кукмара муниципаль районы Гражданлык яклау идарәсе» МКУ | 2018 – 2020 еллар | Кукмара МР бюджеты | 249,3 | 121,7 | 914,7 |
| 4 | Гадәттән тыш хәлләрне һәм табигый бәла-казаларны кисәтү һәм бетерү буенча чаралар | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2018 – 2020 еллар | Кукмара МР бюджеты | 0,0 | 3,7 | 100,0 |